ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.12.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3428**

2026 - 2030 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны раслау турында

2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаның гамәлдә булу срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2026 - 2030 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны расларга(кушымта)
2. Әлеге Закон 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек белән массакүләм мәгълүмат чаралары элемтә бүлегенә «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru)порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

ЗМР Башкарма комитетының
2025 елның 10 декабрендәге
3428 номерлы карары белән
расланды

**2026 - 2030 елларга**
**Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программа**

## 1. Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | 2026 - 2030 елларга Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программа (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон;<br>2025 елның 20 мартындагы«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәоештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2011 елның 7 февралендәге 3-ФЗ номерлы «Полиция турында» федераль закон;<br>2002 елның 25 июлендәге «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында» 114-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2016 елның 23 июнендәге «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасының нигезләре турында» 182-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2006 елның 6 мартындагы «Террорчылыкка каршы тору турында» 35-ФЗ номерлыф Федераль законы;<br>2014 елның 2 апрелендәге «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Россия Федерациясе Бюджет кодексы;<br>2017 елның 11 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>2015 елның 25 апрелендәге «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 33-ТРЗ номерлы ;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш»Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 764 номерлы карары;<br>Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 14 июнендәге 1341 номерлы карары. |
| Программаны | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, |

| | |
|---|---|
| төп эшләүчеләре | Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары (килешү буенча) |
| Программаны башкаручылар | Программаны башкаручылар түбәндәгеләр:<br>- ТР ЗМР хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе;<br>-ЗМР БК мәдәният идарәсе;<br>- ЗМР БК спорт бүлеге;<br>- ЗМР БК яшьләр эшләре бүлеге;<br>ЗМР БК мәгариф идарәсе;<br>- кулланучылар базары бүлеге;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе;<br>- «Зеленый Дол» инвестиция үзәге» ЗМР АУ;<br>Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиясе;<br>-Зеленодольск шәһәр прокуратурасы (килешү буенча);<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең Зеленодольск районы буенча миграция мәсьәләләре бүлеге (килешү буенча);<br>- Транспортта Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан линия идарәсе буенча Зеленый дол станциясендә полиция линия пункты (килешү буенча);<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>- «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ (килешү буенча);<br>-«Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ (килешү буенча);<br>- Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы хәрби комиссариаты (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы буенча Россия җәзаларын үтәтү федераль хезмәте идарәсенең җинаять-башкарма инспекциясе Федераль казна учреждениесенең Зеленодольск районы буенча филиалы (килешү буенча)<br>-Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары;<br>- федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары (килешү буенча);<br>-Зеленодольск муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм урнашкан оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр, сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый оешмалар, төрле ассоциацияләр һәм фондлар;<br>- аерым гражданнар. |

<table>
<tr><td>Программаның максатлары</td><td colspan="7">Зеленодольск муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау, җинаятьчелеккә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм Зеленодольск муниципаль районында җәмәгать тәртибен саклауның нәтиҗәлелеген арттыру,законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгыту, гражданнарның тормышын һәм тынычлыгын саклау дәрәҗәсен арттыру юлы белән җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү өчен нигез булдыру.</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="7">Хокук бозуларны профилактикалау, аларны кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү чараларын гамәлгә ашыру; урамда һәм җәмәгать урыннарында башкарыла торган хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау эшен оптимальләштерү; җәмәгать тәртибен саклауның нәтиҗәлелеген арттыру, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә хокук бозулар кылу сәбәпләрен һәм шартларын бетерү</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру срогы һәм этаплары</td><td colspan="7">2026 - 2030 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары (мең сум)</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="6">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>2027</td><td>2028</td><td>2029</td><td>2030</td><td>Гамәлгә ашыру чорында барлыгы</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>20 543,167</td><td>20 543,167</td><td>20 543,167</td><td>20 543,167</td><td>20 543,167</td><td>102 715,835</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td></td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>6151,0</td><td>6179,3</td><td>6202,6</td><td>6202,6</td><td>6202,6</td><td>30 938,100</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td></td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>26 694,167</td><td>26 722,467</td><td>26 745,767</td><td>26 745,767</td><td>26 745,767</td><td>133 653,935</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | Искәрмә: 2026 – 2030 елларга Программаны финанс белән тәэмин итү күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә, шулай ук район бюджетын үтәү барышында агымдагы ел күрсәткечләренә төзәтмәләр кертелергә тиеш. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>-теркәлгән җинаятьләрнең гомуми санын ел саен 3%ка киметү;<br>-балигъ булмаганнар тарафыннан яки алар катнашында кылынган җинаятьләрнең өлешен 5%ка киметү;<br>-урамнарда һәм җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләрнең гомуми санын 3%ка киметү;<br>- рецидив җинаятьчелек дәрәҗәсен киметергә, ягъни элек җинаять кылган затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләмен 3% ка киметергә;<br>- җәмәгать тәртибен саклау буенча гражданнарның ихтыяри берләшмәләре эшчәнлегенә җәлеп ителгән затлар санын ел саен 2% ка арттыру ;<br>-хокук бозуларны профилактикалау буенча муниципаль системаның нәтиҗәлелеген арттыру, хокук бозуларны кисәтү буенча эшчәнлекне оештыруга предприятиеләрне, учреждениеләрне, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларны, шулай ук иҗтимагый оешмаларны җәлеп итү;<br>-хокук бозуларны профилактикалауны норматив хокукый җайга салуны тәэмин итәргә;<br>- Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча хокук бозуларны профилактикалау субъектлары һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне яхшыртырга;<br>- балигъ булмаган тоткыннарның саны арту темпларын киметергә;<br>- мөлкәт һәм икътисадый җинаятьләр саны арту темпларын киметергә ;<br>-"көнкүреш" җинаятьчелек дәрәҗәсен киметергә,<br>- наркотик һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләр санын киметергә;<br>- миграция агымнарын контрольдә тотуны көчәйтергә, законсыз мигрантлар санын киметергә; |
| Контроль оештыру системасы | Программ чараларын гамәлгә ашыру барышын координацияләү һәм контрольдә тоту Зеленодольск муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе тарафыннан башкарыла. |

## 2. Вәзгыятьне анализлау, Программаның максатларын һәм бурычларын нигезләү

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең стратегик максаты-гражданнарның иминлеге дәрәҗәсен күтәрү, барлык профилактика субъектларының : Зеленодольск муниципаль районы башкарма хакимияте органнары, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм халыкның үзара хезмәттәшлеген оптимальләштерү юлы белән законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгыту.

Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау проблемасын хәл итүгә программа-максатчан якын килүне гамәлгә ашыру криминаль процессларны комплексլы тоткарлауга һәм норматив хокукый базаны камилләштерү, хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чараларын оештыру һәм халыкның барлык төркемнәрен хокук тәртибен тәэмин итүгә җәлеп итү юлы белән криминаль киеренкелек үсешен булдырмауга юнәлдерелгән.

2021-2025 елларда Зеленодольск муниципаль районында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 28 декабрендәге 2586 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау комплекслы программасы» гамәлгә ашырылды (алга таба - Комплекслы программа)

Комплекслы программа чаралары (45 пункт) биш бүлеккә берләштерелде: профилактик һәм оештыру юнәлешендә, халыкның хокукый культурасын күтәрүгә, халыкның алкоголизация һәм наркотиклаштыру дәрәҗәсен киметүгә, җәза үтәүчеләрне ресоциальләштерүгә кагылды. Чаралар хокук саклау эшчәнлеген камилләштерүгә, урамнарда җәмәгать тәртибен саклауга, полиция участок уполномоченныйларының эшен камилләштерүгә, балалар һәм яшьләр арасында хокук бозуларны кисәтүгә, халыкны наркотиклаштыруны кисәтүне оештыруга, полицияне матди-техник яктан тәэмин итүгә, экстремизмны, раса, милли һәм дини дошманлык тудырны кисәтүгә юнәлдерелгән иде.

Хокук бозуларны профилактикалау субъектларының эшчәнлеген координацияләү һәм Комплекслы программа чараларын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту районның Хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе тарафыннан башкарылды.

2021-2023 елларда Зеленодольск муниципаль районында Комплекслы программада катнашучыларның уртак тырышлыгына һәм криминоген киеренкелекне тотрыкландыруга карамастан, уңай тенденцияне саклап калып булмады, 2024 елда теркәлгән җинаятьләр санының артуы шуны күрсәтә.

2021 елда барлыгы 2490 җинаять теркәлгән.

2022 елда – 2445 җинаять.

2023 елда – 2367 җинаять.

2024 елда – 2722 җинаять.

2025 елның 6 аенда – 1140 җинаять.

2025 елның 6 аенда Зеленодольск муниципаль районында 7 кеше үтерү, 10 авыр тән җәрәхәте салу очрагы, 16 караклык, 3 талау һөҗүме, 311 урлау, 311 мошенниклык, 6 җенси кагылгысызлыкка каршы җинаять кылынган. Урамнарда кылынган җинаятьләр структурасында төп өлешен урлау һәм талаулар тәшкил итә.

Мәгълүмати телекоммуникация технологияләрен кулланып мошенниклык гамәлләре саны арта, менә 2021 елда – 371 җинаять, 2022 елда - 450 җинаять, 2023 елда – 506 җинаять, 2024 елда – 608 җинаять, 2025 елның 6 аенда – 316 җинаять.

Наркоситуация катлаулы булып кала. РФ Җинаять кодексының «Наркотик чаралар, психотроп матдәләр яки аларның аналогларын законсыз сатып алу, саклау, ташу, җитештерү, эшкәртү» 228 ст. буенча 2021 елда 200 җинаять ; 2022 елда – 219 җинаять; 2023 елда – 215 җинаять; 2024 елда – 186 җинаять; 2025 елның 6 аенда – 74 җинаять ачыкланган. Хокук саклау органнары тарафыннан кабул ителгән чаралар Зеленодольск муниципаль районы территориясендә наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы торуга юнәлдерелгән.

Иҗтимагый куркынычсызлык торышына гражданнарның аерым социаль яраклашмаган категорияләре аеруча тискәре йогынты ясый, алар арасында караучысыз калган балалар һәм яшүсмерләр, балигъ булмаган хокук бозучылар. 2021 елда балигъ булмаганнар тарафыннан 66 җинаять ; 2022 елда – 98 җинаять; 2023 елда – 55 җинаять; 2024 елда – 60 җинаять; 2025 елның 6 аенда – 25 җинаять кылынган.

Шәһәр халкының тормышына йогынты ясаучы мөһим фактор булып җәмәгать урыннарында кылынган хокук бозуларның кимүе тора. Менә 2021 елда җәмәгать урыннарында 668 җинаять ; 2022 елда – 680 җинаять; 2023 елда – 578 җинаять; 2024 елда – 550 җинаять кылынган.

Проблемаларны хәл итүнең нәтиҗәле механизмы булып Программа максатларын һәм бурычларын төгәл билгеләү, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә хокук бозулар саны артуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча координацияләнгән чаралар исемлеген сайлау белән эшчәнлекне планлаштыруның программалы-максатчан методы тора. Мондый ысулны куллану хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен комплекслы чишүнең өстенлекле юнәлешләрендә ресурс мөмкинлекләрен мобилизацияләргә мөмкинлек бирәчәк.

Программа Зеленодольск муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру буенча төп

чараларның эчтәлеген билгели торган норматив документтан тора. Хокук бозуларны профилактикалау буенча тәкъдим ителгән система Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының, хокук саклау органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм халыкның хокук бозулар, җинаятьчелек, терроризм, наркотик чараларның законсыз әйләнеше һәм башка хокукка каршы гамәлләр белән көрәштә көчләрен берләштерүне күздә тота.

Программаны гамәлгә ашыру халыкның барлык катламнарын көнкүреш җинаятьчелегенә каршы көрәш чараларын тәэмин итүгә җәлеп итү, актив тормыш позициясен формалаштыруга ярдәм итә торган шартлар тудыруга, халык белән, беренче чиратта, балигъ булмаганнар һәм яшьләр белән мәдәни-күңел ачу һәм спорт-массакүләм эш алып баруга ярдәм итү юлы белән хокук бозуларны кисәтүнең нәтиҗәле механизмын булдырырга тиеш. Программа балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең даими мәшгульлек базасында хокук бозуларын профилактикалау системасы инфраструктурасын үстерүгә, балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең, шул исәптән эчке эшләр органнарында исәптә торучы яшьләрнең оешкан ялын һәм ял итүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын күздә тота.

## 3. Программаның максатлары һәм бурычлары, аны гамәлгә ашыру сроклары

Программаның максаты - Зеленодольск муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау, җинаятьчелеккә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм Зеленодольск муниципаль районында җәмәгать тәртибен саклауның нәтиҗәлелеген арттыру , законлылык һәм хокук тәртибен ныгыту, гражданнарның иминлек дәрәҗәсен күтәрү аша җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү өчен нигез булдыру.

Программа тарафыннан түбәндәге төп бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Балигъ булмаган балалар һәм яшьләрнең хокук бозуларын кисәтү, халыкка, барыннан да элек яшьләргә һәм мәктәп яшендәге балаларга әхлакый тәрбия бирүне активлаштыру һәм камилләштерү.

2.Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның һәм иректән мәхрүм ителүгә бәйле булмаган хөкем ителгәннәрнең, шул исәптән балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең социаль адаптациясен һәм реабилитациясен тәэмин итү.

3.Халык арасында , шул исәптән балигъ булмаган балалар һәм яшьләр арасында, алкогольле һәм наркотикларга бәйлелеккә каршы көрәшкә юнәлдерелгән хокук бозуларны профилактикалау эшен активлаштыру.

4. Җәмәгать урыннарында булган хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау эшен оптимальләштерү һәм хокук бозуларны кисәтүгә барлык милек формасындагы предприятиеләрне, шулай ук гражданнарны һәм иҗтимагый берләшмәләрне җәлеп итү.

5. Легаль булмаган миграцияне кисәтү һәм булдырмау.

6.Экстремизмны һәм терроризмны профилактикалау, шул исәптән яшүсмерләр, яшьләр арасында да.

7.Зеленодольск муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны профилактикалау эшен активлаштыру.

8.Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районындагы бүлегенең матди-техник базасын ныгыту.

Программа 2026-2030 елларда гамәлгә ашырыла.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаның чараларын гамәлгә ашыру өчен якынча чыгымнар, аның гамәлдә булу чоры өчен 133 653,935 мең сум тәшкил итә, шул исәптән, Программаның бүлекләре буенча финанслау күләмнәре:

| Программа пунктлары | Финанслау, мең сумнарда | | | | | Чара нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | |
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсе киму | - | - | - | - | - | - |
| Балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау. | - | - | - | - | - | - |
| Хөкем ителүчеләрне иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру | - | - | - | - | - | - |
| Җәмәгать иминлеген тәэмин итүдә эчке эшләр органнары эшчәнлеген оештыру һәм җәмәгать урыннарында хокук тәртибен һәм иминлекне тәэмин итү һәм җинаятьләрне ачу өчен | 20 543,167 (ЗМР бюджеты) | 20 543,167 (ЗМР бюджеты) | 20 543,167 (ЗМР бюджеты) | 20 543,167 (ЗМР бюджеты) | 20 543,167 (ЗМР бюджеты) | 102 715,835 (ЗМР бюджеты) |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| заманча техник чаралар кертү. | | | | | | |
| Урамнарда хокук тәртибен тәэмин итү | 6 151,0 (ТР субвенциясе) | 6 179,3 (ТР субвенциясе) | 6 202,6 (ТР субвенциясе) | 6 202,6 (ТР субвенциясе) | 6 202,6 (ТР субвенциясе) | 30 938,10 (ТР субвенциясе) |
| БАРЛЫГЫ | 26 694,167 | 26 722,467 | 26 745,767 | 26 745,767 | 26 745,767 | 133 653,935 |

Моннан тыш, чыгымнар түбәндәгеләрдән күздә тотыла:

- чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчалардан;
- гамәлдәге законнар белән тыелмаган башка чыганаклардан.
- Программада чагылдырылган программа чараларын гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү тиешле финанс елына район бюджетында программа чараларына ассигнованиеләрраслау шарты белән башкарылырга мөмкин. Тиешле финанс елына район бюджетында программа чараларына ассигнованиеләр булмаса, финанслау район бюджетына өстәмә керемнәр булганда һәм (яисә) район бюджетының башка чыгымнары буенча бюджет ассигнованиеләре кыскартылганда гамәлгә ашырылырга мөмкин.

## 5. Кабул ителгән кыскартулар

МВК - ТР Зеленодольск муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия;
ЗМР БК-Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты;
ИК СП(АҖ БК) -Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары;
СМИ(ММЧ)-Массакүләм мәгълүмат чаралары;
ФБП МУ– «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждение;
ХК – Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районының хәрби комиссариаты;
ОМВД(ЭЭМБ)-Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге;
ЛПП – Транспортта Россия Эчке эшләр министрлыгы Казан линия идарәсенең Зеленый дол станциясендә линия полиция пункты;
ХМҮ – «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге»ДБУ;
ФКХИБ - Зеленодольск шәһәрендә РФ Федераль куркынычсызлык хезмәтенең ТР буенча идарәсе бүлеге;
УИИ - Россия Федерациясе җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Җинаять-башкарма инспекциясе Федераль казна учреждениесенең Зеленодольск районы буенча филиалы;
СЯБ – ЗМРда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге
ЯБ-Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре

бүлеге;
СБ – ЗМР Башкарма комитетының спорт бүлеге;
МИ(УО)-ЗМР БК мәгариф идарәсе;
МИ(УК) - ЗМР БК мәдәният идарәсе;
КББ– Кулланучылар базары бүлеге;
ИҮ – «Зеленый Дол» инвестиция үзәге» ЗМР АУ;
ЗҮРХ - «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе » ДАСИ;
ИК ҖЧҖ -«Идарәче компания» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ;
ГО һәм ГТХ – Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Зеленодольск муниципаль районы буенча идарәсе;
ТКХД – «ТР ЗМР торак - коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ;
ЯКБ -Зеленодольск муниципаль районы буенча дәүләт янгын күзәтчелеге бүлеге;
ЗПНД- «Зеленодольск психоневрология диспансеры» академик В. М. Бехтерев исемендәге РКХ филиалы;
КДН – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия;
ФОМС – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча региональ бүлегенең 14 нче филиалы;
МТТ – мәгълүмати-телекоммуникация технологияләре;
«Форпост»ЗҮ – «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча Зеленодольск яшьләр (студентлар, мәктәп) оешмалары үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе.

## 6. Программаның үтәлешен оештыру һәм аны гамәлгә ашыру барышын контрольдә тоту

Хокук бозуларны профилактикалау субъектлары эшчәнлеген координацияләү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла. Әлеге орган тарафыннан кабул ителә торган карарлар (беркетмәләр) тиешле профилактика субъектлары тарафыннан үтәлә. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында хокук бозуларны профилактикалауның аерым юнәлешләре буенча яисә бу өлкәдә конкрет проблеманы хәл итү өчен эшче комиссияләр (төркемнәр) оештырыла ала. Профилактика субъектларында штаттан тыш нигездә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән хезмәттәшлек итү, Программа чараларының үтәлешен координацияләү һәм алар тарафыннан кабул ителә торган карарларны, аерым алганда, аларга кагылышлы өлештә тормышка ашыруны тәэмин итә торган эшче төркемнәр оештырыла ала. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты эшендә катнашу өчен суд органнары һәм прокуратура органнары вәкилләре үзләренең ризалыгы белән чакырыла ала. Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- хокук бозуларны профилактикалау торышына комплекслы анализ үткәрү һәм алга таба профилактика субъектларына тәкъдимнәр әзерләү;

- Зеленодольск муниципаль районы Башлыгына, җирле үзидарә органнарына профилактик эшчәнлекнең торышы турында мәгълүмат бирү, аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр кертү;
- хокук бозуларны кисәтү, аларны кылуга этәрә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү мәсьәләләре буенча профилактика субъектлары җитәкчеләрен тыңлауны оештыру;
- профилактика субъектлары эшчәнлеген координацияләү:
  -хокук бозуларны кисәтү , аны камилләштерү буенча чаралар эшләү буенча;
  -хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә законнар һәм башка норматив хокукый актлар проектларын әзерләү буенча ;
  - халык, иҗтимагый оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне ныгыту һәм тыгыз хезмәттәшлекне җайга салу буенча.

Программа чараларын вакытында һәм сыйфатлы башкару, аны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан рациональ файдалану өчен муниципаль берәмлекнең хокук бозуларны профилактикалау субъектлары, ведомстволар, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җаваплы («Башкаручылар»бүлегендә күрсәтелгән).

Зеленодольск муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау субъектлары, ведомстволар, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, чаралар үтәлеше өчен җаваплы җирле үзидарә органнары квартал саен, кварталның 15 числосыннан да соңга калмыйча, билгеләнгән тәртиптә аларның үтәлеше турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына мәгълүмат бирәләр. Программаның үтәлеше барышын Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе каршындагы утырышларда, Хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия утырышында даими карау планлаштырыла, аларда Программаны башкаручыларның мәгълүматлары тыңланачак. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгына һәм Зеленодольск муниципаль районы Советына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты ел саен, 1 мартка кадәр, узган елдагы Программаны гамәлгә ашыру турында доклад (11 нче пунктындагы форма буенча) һәм аңлатма язуы) тәкъдим итә. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Программа чараларының вакытында һәм сыйфатлы үтәлешен контрольдә тота.

## 7. Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү

Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- хокук бозуларны социаль профилактикалауның дәүләт системасының нәтиҗәлелеген арттырырга, хокук бозуларны кисәтү эшчәнлеген оештыруга предприятиеләрне, учреждениеләрне, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларны, шулай ук иҗтимагый оешмаларны җәлеп итәргә;
- хокук бозуларны профилактикалауны норматив хокукый җайга салуны тәэмин итәргә;
- Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча дәүләт органнары һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне яхшыртырга;
- кешеләр күпләп җыела торган урыннарны видеокүзәтү камералары белән техник тәэмин итү урамнарда һәм җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләрнең гомуми санын киметергә мөмкинлек бирәчәк;

- балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләмен теркәлгән җинаятьләрнең гомуми саныннан киметергә;
- хөкем ителгән балигъ булмаганнар санының үсеш темпларын киметергә;
- рецидив җинаятьчелек дәрәҗәсен киметергә;
- мөлкәт һәм икътисади җинаятьләр санының үсеш темпларын киметергә;
- «көнкүреш» җинаятьчелек дәрәҗәсен киметергә ;
- исерек хәлдә кылынган җинаятьләрнең чагыштырма күләмен киметергә;
- наркотик һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләр санын киметергә;
- миграцион агымнарны контрольдә тотуны көчәйтергә, законсыз мигрантлар санын киметергә;
- халыкның хокук саклау органнарына ышаныч дәрәҗәсен арттырырга;
- еллар буенча тикшерелгән җинаятьләр санын арттырырга .

## 8. Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

<table>
